Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының бишенче чакырылышының сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы карары

21 май, 2026 ел № 62

Питрәч авылы

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының мактаулы гражданы» исеме турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 28 декабрендәге 301 номерлы карары (Советның 2025 елның 26 февралендәге 383 номерлы карары белән расланган үзгәрешләре белән) белән расланган «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мактаулы гражданы» исеме турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.12 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.12. «Мактаулы гражданин» билгесе түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Өске өлеше - Татарстан Республикасы флагының стилизацияләнгән сурәте. Флаг яшел (өстән), ак (уртадан) һәм кызыл (астан) горизонталь полосалар рәвешендә эшләнгән. Полосалар декоратив беркетмәдә беркетелгән җилфердәп торучы тукыма формасында сурәтләнгән.

Аскы өлеше - рельефлы сурәт белән алтынсу төстәге түгәрәк медальон. Медальон уртасында Питрәч муниципаль районы гербы урнаштырылган: яшел очлы кызыл кырда, өстә алтын чүлмәк, аның өстендә алтын әтәч тора, аны ике көмеш чәшке тотып тора.

Медальонның кырые - нурлы йолдызны хәтерләткән рифланган текстуралы алтынсу түгәрәк рәвешендә эшләнгән.

Язма - медальон әйләнәсендә (тышлыкның аскы өлешендә) рус телендә «ПОЧЕТНЫЙ ГРАЖДАНИН» дип язылган.

Беркетү - медальон флаг сурәте белән кечкенә боҗра һәм уенты ярдәмендә тоташтырылган.

Турыпочмаклы пластинаның арткы ягында киемгә билге беркетү өчен башлы энә бар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов